СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.07.2021г. п.г.т. Аксубаево № 57

Аксубай муниципаль район Советының 2014 ел, 29 октябрь, 233нче карары белән расланган «Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында» 2020 ел, 10 декабрь, 778 нче Указын үтәү йөзеннән Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Аксубай муниципаль район Советының 29.10.2014 ел, № 233 карары белән расланган «Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча башкарылган алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда вазыйфаи затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм бу алыш-бирешләр кылган финанс чараларын алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

1.2. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле

кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча башкарылган алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда вазыйфаи затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук финанс чараларын алу чыганаклары турында белешмәләр Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә законда билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе К.К.Гыйлманов